МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

30.07.2020 г. Казань № под-810/20

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2020 елның 8 апрелендәге под-513/20 номерлы боерыгы белән расланган Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 18 июлендәге 184-ФЗ номерлы федераль законның 1 статьясының 2 пунктындагы «а» пунктчасы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе нигезендә **боерык бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 8 апрелендәге под-513/20 номерлы боерыгы белән расланган Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.3.4 пунктның өченче абзацында «стендта урнаштырыла торган» сүзләреннән соң «һәм «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында» сүзләрен өстәргә;

1.4 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны бастырып чыгару чыганакларын да күрсәтеп) Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.5 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Әлеге регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт хезмәте – федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру эшчәнлеге, ул дәүләт хезмәтләрен күрсәтә торган органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актларында һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә мөрәҗәгать итүчеләрнең рәсми мөрәҗәгатьләре буенча гамәлгә ашырыла;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе бозылуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең әлеге мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдаланган вакытта дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яисә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 16 статьясының 11 өлешендә каралган оешмалар яисә аларның хезмәткәрләре тарафыннан мөрәҗәгать итүченең бозылган хокукларын яисә законлы мәнфәгатьләрен торгызу яки яклау турында таләп итүе;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яисә муниципаль учреждениенең оешу-хокук формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торган), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирә торган һәм «бер тәрәзә» принцибы буенча, шул исәптән электрон формада да, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма;

«бер тәрәзә» принцибы – мөрәҗәгать итүче дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү турында тиешле рәсми мөрәҗәгать белән яки 210-ФЗ номерлы федераль законның 151 статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгать белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтелә торган, ә дәүләт хезмәтләрен күрсәтә торган органнар яисә муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган органнар белән үзара хезмәттәшлек итү мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка гына норматив хокукый актлар

һәм хезмәттәшлек итү турындагы килешү нигезендә күпфункцияле үзәк тарафыннан гамәлгә ашырыла торган принцип;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу хатасы, басма хата, грамматик яки арифметик хата).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать турында сүз бара. Гаризаның киңәш ителә торган формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.»;

2 бүлектә:

2.1 пунктта «Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләп билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Балалы гражданнарга дәүләт пособиеләре турында» 1995 елның 19 маендагы 81-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 81-ФЗ номерлы федераль закон) 12.1 статьясы, 12.2 статьясы;

«Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 48-ФЗ номерлы федераль закон) 31 статьясы;

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Балалы гражданнарга дәүләт пособиеләрен билгеләү һәм түләү тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2009 елның 23 декабрендәге 1012н номерлы боерыгы (алга таба – Россия Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 1012н номерлы боерыгы белән расланган Тәртип);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2009 елның 8 маендагы 287 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы турындагы нигезләмә (алга таба – Нигезләмә);

2.2 пунктта «Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләп билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Нигезләмәнең 3.3 пункты»;

2.5 пунктта «Стандартка карата таләп эчтәлеге» графасында:

өченче абзацны гамәлдән чыккан дип танырга;

егерме бишенче абзацта «63-ФЗ номерлы федераль законның» сүзләрен «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:<br>бала яшәгән урын буенча аның опекуны (попечителе), тәрбиягә алган ата-анасы белән яшәве турында белешмә (РФ Эчке эшләр министрлыгыннан);<br>балага айлык пособие түләүне туктату турында территориаль социаль яклау органыннан белешмә (ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан);<br>иминиятләштерүче сыйфатында Фонд органнарында теркәлү турында Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органыннан белешмә яки качак таныклыгы күчермәсе (РФ Социаль иминиятләштерү фондының ТР буенча Төбәк бүлекчәсе ДУ);<br>инвалидлык билгеләнү фактын раслый торган белешмә, – инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алган затлар өчен (РФ Пенсия фондыннан). | |

| | | |
|---|---|---|
| | Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән. Югарыда саналган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуында торган оешмалар карамагында булган документларны мөрәҗәгать итүчедән таләп итү тыела.» | |

3 бүлектә:

3.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Бүлек белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон формада түбәндәгеләрне бирү турында сорап, рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

бала яшәгән урын буенча аның опекуны (попечителе), тәрбиягә алган ата-анасы белән яшәве турында белешмә (РФ Эчке эшләр министрлыгыннан);

балага айлык пособие түләүне туктату турында территориаль социаль яклау органыннан белешмә (ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан);

иминиятләштерүче сыйфатында Фонд органнарында теркәлү турында Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органыннан белешмә яки качак таныклыгы күчермәсе (РФ Социаль иминиятләштерү фондының ТР буенча Төбәк бүлекчәсе ДУ);

инвалидлык билгеләнү фактын раслый торган белешмә, – инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алган затлар өчен (РФ Пенсия фондыннан).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.»;

5 бүлектә:

атамасында «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең,» сүзләреннән соң «210-ФЗ номерлы федераль

законның 16 статьясының 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлегенә (В.О.Васильева) эш көннәрендә исәпләнә торган өч көнлек срокта әлеге боерыкны, имзалаганнан соң, дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары А.М.Әсәдуллинага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
Министр Р.Т.Борһанов